| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2016ел, 22 январь** **№ 3**

Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле булган хокукый актлар регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга салучы законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 43.1 статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында " 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль районга керүче җирлекләрдән мәгълүмат җыю буенча, Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле булган хокукый актлар регистрын алып бару мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешү нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы башлыгы белән төзелгән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен 2016 елның 21 гыйнварында Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актларын һәм алар турында белешмәләрне җибәрү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешү нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне җибәрү буенча эш барышында Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге регламентына таянып, муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җыю һәм җибәрү буенча эш итәргә., Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы башлыгының 2016 елның 20 гыйнварындагы 14 номерлы карары белән расланган.

2. Муниципаль район Советына, авыл җирлеге башлыгына һәм авыл җирлеге башкарма комитетына муниципаль норматив хокукый актларны, шулай ук регистрга кертелергә тиешле белешмәләр җибәрү өчен җаваплы итеп җирлек башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарын (сәркәтибен) билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының

рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Әлмәт авыл җирлеге
Башкарма комитеты житәкчесе Д. Ә. Газизов